УПРАВЛЕНИЕ
ПО ОХРАНЕ И
ИСПОЛЬЗОВАНИЮ
ОБЪЕКТОВ
ЖИВОТНОГО МИРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ
ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ
ҺӘМ АЛАРДАН
ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ

---

| **Приказ** | | **Боерык** |
|---|---|---|
| 28.02.2017 | г. Казань | № 23-од |

Татарстан Республикасының
хайваннар дөньясы
объектларын саклау һәм
алардан файдалану Идарәсенең
21.12.2015 елдан 179-од
номерлы «Татарстан
Республикасында сәнәгый
балыкчылыкны оештыру өчен
балык тоту бүлемтеген алу
хокукына килешүнамә төзү
бәйгесен уздыру буенча
Комиссия булдыру турында»гы
боерыгына үзгәрешләр кертү
турында

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсенең норматив-хокукый актларын, кануннар белән тәңгәл китерү максаты белән, боерам:

1. Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсенең 21.12.2015 елдан 179-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасында сәнәгый балыкчылыкны оештыру өчен балык тоту бүлемтеген алу хокукына килешүнамә төзү бәйгесен уздыру буенча Комиссия эшчәнлеге Тәртибенә киләсе үзгәрешләр кертергә:

3нче пунктны киләсе эчтәлекле “ Комиссия Рәисе булып, бәйге Оештыручының вәкиле билгеләнә.” яңа юл белән тулыландырырга;

5нче пункттагы 2нче кызыл юл “г” кече пунктында “гариза бирүченең гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны тапшыру көненнән” сүзләрен

“гаризалы конвертларны ачу һәм гаризалар белән  файдаланырга рөхсәт бирү” сүзләренә алмаштыру.

2. Бу боерыкның үтәлүен тикшерүне Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсе башлыгы урынбасары Ю.Б.Матвеевка тапшырырга.

Идарә башлыгы Ф.С.Батков